МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.04.2026 Казан ш. № под-647/26

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 11 мартындагы под-431/16 номерлы «Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президентының « Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында » 2010 елның 25 августындагы 569 номерлы Указына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә б о е р а м:

1. «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында» 11.03.2016 № под-431/16 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 22.03.2018 ел № под-519/18, 24.10.2022 ел № под-1793/22, 11.05.2023 ел №под-967/23, 05.09.2023 ел № под-1549/23, 06.06.2024 ел № под-1150/24 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия Министрлыкның норматив хокукый акты белән төзелә. Күрсәтелгән акт белән комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, комиссия рәисе, аның урынбасары, Секретаре билгеләп куела һәм комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

2.2 пунктының «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) министрның беренче урынбасары (Комиссия рәисе), министр урынбасары (Комиссия рәисе урынбасары), министрлыкның кадрлар сәясәте бүлегенең

коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (комиссия секретаре), министрлыкның юридик бүлеге, Министрлыкның министр билгеләгән башка бүлекчәләре хезмәткәрләре;»;

3.1 пунктының «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә уздырылган тикшерү йомгаклары буенча министрның дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын һәм дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең үтәлешен, тикшерү материалларын (шул исәптән коррупциягә каршы тору өлкәсендә "Посейдон" дәүләт мәгълүмат системасын кулланып) тапшыруы:

Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәдә каралган дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләрне дәүләт хезмәткәрләренә бирү турында;

дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәве турында; »;

3.11 пунктының «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләр дөрес һәм Тулы дип билгеләргә;».

2. Министрлыкның Мәгълүмати технологияләр һәм иминлек үсеше бүлегенә (И.Н.Сарманов) әлеге боерыкны Министрлыкның рәсми сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлегендәге «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе» / «Норматив документлар» өлешендә урнаштырырга.

3. Кадрлар сәясәте бүлегенә (Г.Х.Гатауллина) әлеге боерыкны Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән срокта Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвен тәэмин итәргә.

4. Бу боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Министр И.Г.Һадиуллин